ГЛАВА
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.12.2025 ел Баулы шәһәре № 193

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Новозареченск авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар билгеләү турында

Федераль законның «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулар, (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә, Баулы муниципаль район Советының 2018 елның 3 июлендәге 160 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Уставының 17 статьясы нигезендә

КАРАР ИТӘМ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Новозареченск авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре (алга таба - Проект) проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар уздыруны билгеләргә.

2. Проект буенча иҗтимагый фикер алышулар инициаторы – Баулы муниципаль районы Башлыгы.

3. Иҗтимагый фикер алышуларны уздыруны 2025 елның 4 декабреннән 2025 елның 17 декабренә кадәр билгеләргә.

4. Иҗтимагый фикер алышуларда каралырга тиешле проект экспозициясен 2025 елның 4 декабрендә ачарга:

4.1. Экспозицияне уздыру урыны:

- Татарстан Республикасы Баулы районы Новозареченск авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында: Татарстан Республикасы, Баулы районы, Новозареченск авылы,

Вахитов ур., 15 й.адресы буенча;

- Николашкино авылының Совет ур., 38А йорт адресы буенча урнашкан бинада;

- Измайлово авылының Беренче Май урамы, 17а адресы буенча урнашкан бинада ;

- Дмитриевка авылының Чапаев ур., 14а адресы буенча урнашкан бинада,

-Таллы Күл авылының Вахитов ур., 15 йорт адресы буенча урнашкан бинада

- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә www.bavly.tatarstan.ru Баулы муниципаль районы сайтында.

4.2. Экспозицияне карау режимы:

- Татарстан Республикасы Баулы районы Новозареченск авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында: Татарстан Республикасы, Баулы районы, Новозареченск авылы, Вахитов ур., 15 й.адресы буенча;

- Николашкино авылының Совет ур., 38А йорт адресы буенча урнашкан бинада;

- Измайлово авылының Беренче Май урамы, 17а адресы буенча урнашкан бинада ;

- Дмитриевка авылының Чапаев ур., 14а адресы буенча урнашкан бинада,

-Таллы Күл авылының Вахитов ур., 15 йорт адресы буенча урнашкан бинада.

Мәскәү вакыты белән 8.30 дан 11.30 сәгатькә кадәр, 13.30 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр.

5. Җәмәгать фикер алышуларында катнашучылар 2025 елның 4 декабреннән 2025 елның 17 декабренә кадәр эш көннәрендә, Мәскәү вакыты белән 8.30 дан 11.30 га кадәр, 13.30 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр җәмәгать тыңлауларында каралырга тиешле проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

-язмача рәвештә җәмәгать тыңлауларын оештыручыга: Баулы шәһәре, Куйбышев урамы, 20 йорт, 101 каб. адресы буенча;

- по электронной почте Bauly.arch@mail.ru.

6. Ижтимагый фикер алышуларны оештыручы итеп Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты (алга таба - җәмәгать фикер алышуларын оештыручы) билгеләргә.

7.Ижтимагый фикер алышуларны оештыручыга:

7.1. Проектны карау буенча иҗтимагый фикер алышулар уздыруны тәэмин итәргә;

7.2. Проект буенча иҗтимагый фикер алышулар башлану турында Татарстан Республикасы Баулы муниципаль берәмлеге Новозареченск авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында мәгълүмат стендында Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге сайтында (www.Bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга;

7.3. Экспозицияләрне Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Новозареченск авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында 2025 елның 2 декабреннән 17 декабренә кадәр эш көннәрендә, Мәскәү вакыты белән 8.30 дан 11.30 сәгатькә кадәр, 13.30 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Баулы муниципаль районы сайтында www.bavly.tatarstan.ru оештырырга;

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы башлыгы И.И. Гозәеров